МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.03.2017 Казан шәһәре № под-428/17

«Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә укытуның иң яхшы практикасы» гранты турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 - 2017 уку елына эш планын раслау турында» 2016 елның 20 июлендәге №под - 1397/16 боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016-2017 уку елына эш планы нигезендә, Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә балаларны укыту буенча Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының иң яхшы педагогик коллективларын ачыклау һәм бүләкләү максатларында б о е р а м:

1. «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә укытуның иң яхшы практикасы» грантын булдыру.

2. Кушымта итеп бирелә торган:

2.1.2017 елда «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә укытуның иң яхшы практикасы» грантын алуга конкурс (алга таба-Конкурс) әзерләү һәм үткәрү буенча чаралар планын расларга

2.2. «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә укытуның иң яхшы практикасы» гранты турында Положениене расларга

3. Конкурсны 2017 елның 10 апреленнән 21 апреленә кадәр оештырырга һәм үткәрергә.

4. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы затларга әлеге боерыкның 2.1 пункты белән расланган планның үтәлешен тәэмин итәргә.

5. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә (Г. Ф. Гатиятуллина) конкурсны оештыруны һәм уздыруны финанслауны тәэмин итәргә.

6. Милли мәгариф бүлегенә (А. С. Шәрипова) эш көннәрендә исәпләнгән өч эчендә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

7. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.Р.Мөхәммәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-
министр урынбасары, министр Э.Н.Фаттахов

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
«16» 03.2017 ел, № под-428/17
боерыгы белән

2017 елда «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә укытуның иң яхшы практикасы» грантын алуга конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча
Чаралар планы

| № | Чара | Үткәрү вакыты | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Конкурсны әзерләү һәм үткәрү белән гомуми җитәкчелек | 2017 елның март - апрель айлары | И. Р. Мөхәммәтов<br>Г. Х. Исмәгыйлева |
| 2 | Конкурсны үткәрү буенча смета төзү | 2017 елның 25 мартына кадәр | Г. Ф. Гатиятуллина. Г.К. Имамова |
| 3 | Эксперт комиссиясенең Грантка дәгъва кылучы мәгариф оешмаларына чыгу графигын төзү | 2017 елның 7 апреленә кадәр | Г. Х. Исмәгыйлева<br>А. С. Шәрипова<br>Р.Р Шәмсетдинова |
| 4 | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтында бәйге турында норматив-методик, материалларны, Грантка дәгъва кылучыларның расланган исемлеген урнаштыру | Конкурс барышында | Л. А. Гайфуллина<br>А. А. Кравцов |
| 5 | Эксперт комиссиясе эшен оештыру | 2017 елның 10 апреленнән 21 апреленә кадәр | Г. Х. Исмәгыйлева<br>А. С. Шәрипова<br>М. Х. Әсәдуллин |
| 6 | Грант алучыларның исемлеген формалаштыру | 2017 елның 24 апреленә кадәр | Республика конкурс комиссиясе |
| 7 | Бәйгене үткәрү көннәрендә фото һәм видеога төшерү, массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан конкурс барышын яктыртуны оештыру. | 2017 елның 10 апреленнән 21 апреленә кадәр | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат хезмәте |

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
«16» 03.2017 ел, № под-428/17
боерыгы белән

**«Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында Татарстан Республиканың дәүләт телләрендә укытуның иң яхшы практикасы» гранты турында Положение**

## 1. Гомуми положениеләр

1.1.«Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә укытуның иң яхшы практикасы» грантын (алга таба - Грант) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба - Министрлык) боерыгы белән гамәлгә куела.

Чарада грантны гамәлгә куючы (грант бирүче), Грантка дәгъва кылучы һәм Грант алучы катнаша.

Грантны гамәлгә куючы (грант бирүче) - грантлар бирү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы министрлык.

Грантка дәгъва кылучы - Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм билгеләнгән тәртиптә үз эшчәнлеген алып баручы, гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы дәүләт яисә муниципаль гомуми белем бирү оешмасы (алга таба - гомуми белем бирү оешмасы).

Грант алучы - әлеге Положениедә билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килә торган, конкурс сайлап алуын узган һәм 1-10 нчы урынны алган гомуми белем бирү оешмасы.

Грант - Грант алучыларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә белем бирүнең сыйфатын күтәрүгә, педагогик коллективны һөнәри үстерүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен 1000 000 (бер миллион) сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү.

Грант алучы грантта 3 елга 1 тапкыр гына катнашырга хокуклы.

1.2. Грантка сайлап алу конкурсының максаты – укучыларны Татарстан дәүләт телләрендә укыту сыйфатын күтәрү, шушы юнәлештә эшләүче гомуми белем бирү оешмаларының Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә эшне оештыруга инновацион якын килү буенча уңай тәҗрибәсен тарату, Татарстан Республикасы дәүләт телләрен популярлаштыру.

Сайлап алу конкурсының бурычы –Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә белем бирү процессын югары сыйфатлы итеп оештырган белем бирү оешмаларын ачыклау һәм бүләкләү.

## 2. Грантка сайлап алу өчен гаризалар кабул итү һәм конкурс үткәрү тәртибе

2.1. Грантка сайлап алу конкурсы Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән митнистрлыгы боерыгы нигезендә уздырыла.

2.2.Грант бирүче Министрлыкның рәсми сайтында гаризалар кабул итү (алга таба - Конкурс) һәм грант алуга конкурс сайлап алу үткәрү тәртибе турында игълан итә.

2.3.Грантта катнашучылар, конкурста катнашу өчен, 2017 елның 7 апреленә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының мәгариф идарәсе (бүлеге) җитәкчесе тарафыннан расланган гаризаны Gayfullina.Leysan@tatar.ru электрон адресына җибәрәләр

Гаризаны 2017 елның 7 апреленнән дә соңга калып тапшырган очракта, грантка дәгъва кылучы конкурста катнашу хокукыннан мәхрүм ителә.

2.4.Конкурсны оештыру-методик яктан тәэмин итүне һәм уздыруны, рәис, җаваплы сәркатиб һәм Республика комиссиясе әгъзалары составында Республика комиссиясе (алга таба - Республика комиссиясе) гамәлгә ашыра.

2.5.Республика комиссиясенең персональ составы Министрлык боерыгы белән раслана.

2.6.Республика комиссиясе:

массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка ысуллар аша конкурсны үткәрү шартлары, тәртибе һәм вакытытурында игълан итә;

катнашучылардан гаризалар кабул итә;

эксперт комиссиясе туплый һәм эшен оештыра;

бәйгене оештыра;

конкурска йомгак ясый;

конкурска йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештыра;

конкурс нәтиҗәләрен бастырып чыгаруны оештыра.

2.7. Республика комиссиясе карарлары өчен катнашучыларның күпчелеге тавыш биргән очракта, алар кабул ителгән дип санала,. Тавышлар тигез булган очракта, Республика конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

2.8. Грантка дәгъва кылучыларның конкурс критерийларына туры килүенә экспертиза ясау өчен рәис һәм комиссия әгъзалары составында эксперт комиссиясе төзелә.

2.9. Эксперт комиссиясенең персональ составы Министрлык боерыгы белән раслана.

2.10.Республика эксперт комиссиясе утырышлары кирәк булган саен уздырыла һәм анда  комиссия составының яртысыннан артыгы катнашса гына, тулы хокуклы  булып санала.

2.11.Экспертлар сыйфатында:

Министрлык;

Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты;

мәгариф идарәсенең муниципаль органнары;

педагогик уку йортлары  вәкилләре;

гомуми белем бирү оешмалары педагоглары җәлеп ителергә мөмкин

2.12.Экспертиза вакытында тәэмин ителә:

бәяләү критерийлары нигезендә белем бирү оешмасы эшчәнлеген бәяләүнең объектив булуы;

конфиденциальлек (шул исәптән конкрет катнашучыны бәяләүдә катнашмаган эксперт комиссиясе әгъзаларына карата да).

2.13.Эксперт комиссиясе 10 апрельдән 21 апрельгә кадәр, мәгариф оешмаларына барып, әлеге Положениедә расланган критерийлар нигезендә, грантта катнашучыларның эшчәнлегенә  бәя бирә.

Баллар эксперт битләренә кертелә, экспертлар тарафынна имзалана  һәм эксперт комиссиясе рәисенә тапшырыла.

Эксперт битләре нигезендә грантка дәгъва кылучиларның  рейтингы төзелә.

Эксперт комиссиясе рәисе һәм кмиссия әгъзалары кул куйган Рейтинг Республика конкурс комиссиясенә тапшырыла.

2.14 . Конкурс йомгаклары буенча республика комиссиясе 2017 елның 24 апреленә кадәр грантка дәгъва кылучылар рейтингында 1-10 нчы урынны алган 10 белем бирү оешмасыннан грант алучылар исемлеген төзи.

2.15. Грант бирүче 2017 елның 25 апрелендә Министрлык сайтының «Программалар һәм Проектлар» бүлегендә «Укытучыларга грантлар»/ «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә укытуның иң яхшы практикасы» бүлекчәсендә грант алучыларның расланган исемлеген урнаштыра.

## 3. Конкурс сайлап алу критерийлары

3.1.Конкурс Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә белем алучы укучыларны укыту буенча Грантка дәгъва кылучылар эшчәнлеген, экспертлар бәяләве рәвешендә, гомуми белем бирү оешмаларына барып, турыдан-туры бәяләү формасында үткәрелә.

3.2.Грант алуга конкурс сайлап алу критерийлары:

татар телендә укыту әдәбияты һәм укыту-методик комплектлар белән тәэмин ителеш (максималь баллар саны-5);

Татарстан Республикасының ике дәүләт телен белүче педагоглар өлеше (максималь баллар саны-5);

гомуми башлангыч белем, төп гомуми  һәм урта гомуми белем Федераль дәүләт белем бирү стандартларында билгеләнгән, предметлы өлкәгә кертелгән уку предметларын татар телендә укыту (максималь баллар саны-10);

гомуми белем  преметлары буенча төп дәүләт имтиханнарын (татар теле һәм әдәбиятыннан кала) татар телендә тапшырган укучылар булу (максималь баллар саны-10);

мәктәп укучыларының республика олипиадасының йомгаклау этабында җиңгән укучылар булу (максималь баллар саны-10);

Бөтенроссия “Илһам” яшь шагыйрьләр һәм язучылар конкурсында,  ”Туган тел” Бтенроссия мастер-класслары конкурсында, татар теле һәм әдәбияты укытучыларының Бөтенроссия крнкурсында катнашу нәтиҗәләре(максималь баллар саны-10);

балаларны татар (рус) телләренә өйрәтүнең нәтиҗәлелеге: балаларның татар һәм рус телләрен практик куллана белүе, (балалар белән әңгәмәләр, дәресләр, дәрестә тыш чараларда булу нәтиҗәсендә ачыклана) (максималь баллар саны-10);

башлангыч һәм төп гомуми белем бирү программаларында гомуми белем бирү дисциплиналарының националь-региональ компоненты булу  һәм үтәлү (максималь баллар саны-5);

гомуми белем бирү предметлары буенча татар телендә эш дәфтәрләре алып бару (максималь баллар саны-5);

кабинетларда этномәдәни-региональ компонентны чагылдыручы предметлы - үстерешле мохит, шул исәптән, программа-методик материаллар булу (максималь баллар саны-10);

гомуми белем бирү оешмаларында Татарстан Республикасы телләренә өйрәтү буенча белем бирү оешмасы педагогларының авторлык программалары булу һәм эштә кулану (максималь баллар саны-5);

3.3.  Баллар һәр критерий буенча исәпләнә һәм кушыла. Эксперт комиссиясе әгъзалары конкурс сайлап алуының һәр критерие буенча гомуми белем бирү оешмасына куйган баллар суммасы нигезендә грантка дәгъва кылучыларның рейтингын төзи.

3.4.  «Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә укытуның иң яхшы практикасы» гранты рейтингта 1-10 урынны алган мәгариф оешмаларына бирелә.

## 4. Грантны финанслау

Грант бирү максатларында субсидия бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.